ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11 март 2024 ел № 1506

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 22 гыйнварындагы 324 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы Карары, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 22 гыйнварындагы 324 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе хезмәткәрләренең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенең федераль дәүләт граждан хезмәткәрләренең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсендә эшләүчеләрнең балалары өчен: бер укучыга туклану бәясе 1-4 сыйныфлар өчен – 115,97 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 118,82 сум;»;

2) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Башкарма комитетның мәгариф идарәсенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

1) Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформадан (алга таба – ЕЦП) файдаланып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында мәгълүмат җибәрү;

2) ЕЦПдан файдаланып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә мәгълүмат алу.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов